**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 18 ноябрендәге 4008 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2015 елның 26 июнендәге 2544 номерлы, 2015 елның 16 декабрендәге 4368 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетында кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 26 июнендәге 2544 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр төзү хокукына сатулар үткәрү тәртибе турында»гы карарынының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының2016 елның 16 июнендәге 2451 номерлы, 2017 елның 1 мартындагы 539 номерлы, 2017 елның 16 августындагы 3163 номерлы, 2018 елның 12 гыйнварындагы 77 номерлы, 2018 елның 15 октябрендәге 5268 номерлы, 2019 елның 28 маендагы 1944 номерлы, 2021 елның 26 февралендәге 483 номерлы, 2021 елның 6 декабрендәге 3211 номерлы, 2023 елның 17 июлендәге 2008 номерлы, 2023 елның 22 сентябрендәге 2816 номерлы, 2024 елның 12 апрелендәге 1529 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 2699 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2 номерлы кушымтасынатүбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр төзү хокукына ачык аукцион уздыру комиссиясе составыннан Р.Р.Шәфигуллинны, М.Ф.Никитинаны чыгарырга;

1.2. Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр төзү хокукына ачык аукцион уздыру комиссиясе составына түбәндәгеләрне кертергә: комиссия рәисе буларак – И.С.Шакиров, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары, комиссия әгъзасы буларак – Р.Ф.Сабитов, Казан шәһәре Башкарма

комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсенең финанс-килешүләр бүлеге башлыгы.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 16 декабрендәге 4368 номерлы «Шәһәр белән бәйле очрак барлыкка килгәндә Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр шартларын үтәүне тәэмин итү комиссиясе турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 25 апрелендәге 1424 номерлы, 2017 елның 2 августындагы 2973 номерлы, 2022 елның 25 августындагы 2825 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 2699 номерлы, 2025 елның 14 февралендәге 373 номерлы, 2025 елның 8 августындагы 2568 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Шәһәр белән бәйле очрак барлыкка килгәндә Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр шартларын үтәүне тәэмин итү комиссиясе составыннан Р.Р.Шәфигуллинны чыгарырга;

2.2. Шәһәр белән бәйле очрак барлыкка килгәндә Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр шартларын үтәүне тәэмин итү комиссиясе составына комиссия рәисе буларак Казан шәһәре Башкарма комитетының Җитәкчесе И.С.Шакировны кертергә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**урынбасар** **И.В.Куляжев**